


# *Муса Җәлил – каһарман шагыйрь*

# Тест сораулары

1. Муса Җәлилнең туган елы:
   А) 1908 – 15нче февраль
   Б) 1906 – 15нче февраль
   В) 1903 – 15нче февраль
2. Муса Җәлил кайда туган?
   А) Казан шәһәре
   Б) Оренбург өлкәсе Мостафа авылы
   В) Мордва республикасы Сыркыды авылы
3. Беренче шигырьләрен ул нинди псевдоним белән бастыра?
   А) Кечкенә Муса
   Б) Кечкенә Җәлил
   В) М.Җәлил
4. “Кызыл ромашка” шигырен кем язган?
   А) Габдкулла Тукай
   Б) Муса Җәлил
   В) Фатих Кәрим
5. Бу әсәрләрнең кайсыларын М. Җәлил иҗат иткән?
   А) “Көйләрем”
   Б) “Җырларым”
   В) “Моңнарым”

# Дөрес җаваплар:

1 – Б

2 – Б

3 – Б

4 – Б

5 - Б

# Билге куегыз:

0 хата – “5”

1 хата – “4”

2-3 хата - “3”

# Сүзлек өстендә эш

- **Юл чаты** – берничә юл кушылган урын, перекресток
**Хәят** – тормыш, жизнь
- **Юлчы** – юлда баручы, путник
- **Дым** - юеш җир, влага

Бу сүзтезмәләрне сурәтләү чаралары буларак эпитетларга һәм сынландыруларга бүлегез:


**Карт имән,**
**батыр хезмәт,**
**имән җырлый,**
**яшел чуклы,**
**җылы бирә,**
**имән бүләкләгән**


**Эпитет** –

әдәби ачыклау. Әйбер, күренеш, хәрәкәтне аңа хас булмаган сыйфат ярдәмендә бәяләү.

**Сынландыру** -

җансыз предметны, күренешне җанлы итеп күрсәтү.





Имән

# Имән

Юл чатында ялгыз гына
Үсеп утыра бер карт имән.
Тирә-ягы яшел чирәм,
Ботаклары җиргә тигән.

Таң җилләре җилфер-җилфер
Җилфердәтә яфракларын.
Имән җырлый, искә төшереп,
Шаулап үткән яшь чакларын.

Мең ел элек кемдер монда
Җир казыган, тир тамызган.
Һәм беренче кат иманнең
Яшәү иртәсен кабызган.

Кем дә белми ул кешене,
Игенчеме, бакчачымы,
Яшеллек һәм хәят сөйгән
Батыр хезмәт патшасымы?

Кем булса да, туфрагында

Җир саклаган анын тирен.

Һәм карт имән гомре белән

Бүләкләгән бу эш ирен.

Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы — моңлы җырчы
— Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны,
Кавыштыра айлы кичтә
Яшрен утта янганнарны.

Юл күрсәтә адашканга
Имән кышкы бураннарда.
Җәен татлы дымын эчерә
Кырда урак урганнарга.

Бәхетле син, ерак илдәш,
Хезмәтеңдә мин баш иям.
Һәйкәл булып яшьлегеңдә
Үскән монда бу карт имән.

Җирдә кеше торса торсын,
Эзе калсын тирән булып,
Үзе үлсә, эше калсын
Мең яшәрлек имән булып.

| Имән | Кеше |
| --- | --- |
| Юл чатында, ялгыз, карт.<br>Ләкин: аның тирә-ягы чирәм, аны таң җиле иркәли.<br>Яшь чагы (искә төшерә): шаулы, гөрләп торган,<br>Кемдер аңа гомер биргән,<br>Ул нинди кеше? | Матурлыкны яратучы, җир казучы, тир тамызучы хезмәт патшасы |
| Шуның өчен | |
| Имән – җырчы ял иттерә, Җил-яңгырдан саклый, кырда эшләгәннәрне ял иттерә, кавыштыра, адашканга юл күрсәтә, дымын эчерә | |
| Һәйкәл | Кешегә |

Нәтиҗәле эшегез өчен рәхмәт!